**“ Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы**
**Усман Әлмеев исемендәге Акъегет  гомуми төп белем бирү мәктәбе”**
**муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

# Акъегетем – туган авылым.

Эшнең авторы: 9 нчы  сыйныф укучысы
Миннәхмәтова Зәринә Расих кызы
Җитәкче: татар теле һәм
әдәбият  укытучысы
Закирова Дания Минулла  кызы

Акъегет авылы,  2020 ел.

# Кереш

Акъегетем, туган авылым,
Тик бер көнгә синнән  китсәм,
Сагынып кайтам, ашыгып кайтам.
Күбрәк торган саен читтә
Сине ныграк мин яратам.

Әйе, бик хак, матур сүзләр. Минем дә киләчәк буын өчен игелекле эш башкарасым килде һәм, иң кулае дип, фәнни-эзләнү эше язуны сайладым. Илһам чыганагы, яшәргә көч һәм дәрт бирүче күңел маягы булган туган авылыбыз тарихы турында язганда баштан төрле уйлар кичте. Шуларны башка укучылар күңеленә дә җиткерәсем килә.

Туган нигезне, гаиләне һәм төбәкнең тарихын өйрәнеп, андагы горурланырлык вакыйгаларны, күренешләрне кечкенәдән сеңдергәннән соң гына балаларны патриотик гражданнар итеп тәрбияләргә мөмкин дип уйлыйм. Шулай итеп, эзләнү-тикшеренү эшемнең **максаты** - Акъегет авылының тарихын өйрәнү, авылдашларымда туган төбәгебезгә карата кызыксыну уяту. Шул максаттан чыгып, эшемдә түбәндәге **бурычлар**ны үтәргә уйладым.

1) Акъегет  авылының барлыкка килү тарихын ачыклау;
2) Барлык чорда авылда яшәүчеләрнең исемлеген барлау  һәм авылның тормышын, көн-күрешен күзаллау;
3) Авыл тарихында халкының горурлыгы булып саналырлык вакыйгаларны, шәхесләрне ачыклау.

## Төп өлеш

Туган Ил ул синең  туган йортыңнан башлана.Шулай булгач тарихны өйрәнү -  ул туган авылыңның тарихын өйрәнүдән башланырга тиеш.Аны белү – ул минем бурычым.

Туган авылым Акъегет-бик борынгы авылларның берсе.Аның 700-800 еллык тархы бар.Безгә билгеле булганча,Болгарларга 1223нче  елдаТатар-Монгол Чыңгыз хан,1236нчы елда Батый хан,1361 нче елда Булак – Тимер гаскәрләре  һөҗүм итәләр. Шулай да Болгар  шәһәре һәм авыллары яңадан торгызыла. Болгар халкы шушы изелүләрдән, талаулардан XIV гасырның икенче яртысында Казансу, Мишә, Зөя елгалары буйларына күчеп китәләр. Шулай итеп, безнең борынгы бабаларыбыз Идел буйлап килеп, Бүшәрмә елгасына чыкканнар. Аның түбән агымы, эчу өчен су чыганаклары булган яр буена урнашырга карар иткәннәр.

Тарих галиме Х.Г.Гимади “Казан артына һәм Идел аръягына болгарларны беренче башлап күчеп утырулары XIII гасырнын 30 – 40 нчы елларына (ягъни 1236 нчы елдан соң) туры килә “ – дип яза һәм бу җирлектә күп кенә татар авылларына шул заманда нигез салынуын әйтә . Менә шушы татар авыллары арасында минем туган авылым Акъегеткә дә нигез салына.Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда,  авылны Казан артындагы Мәңгәр якларынан килгән Акъегет , Әлмәмәт һәм Ишмәмәт дигән өч кеше нигезләгән дип әйтәләр. Ә икенче берәүләр исә, Акъегет монда, ягъни авылда туган беренче бала дип тә сөйлиләр. Бу язмалар документаль чыганакларга нигезләнгән.Филология фәннәре докторы Фирдәвес Гарипованың “ Авыллар һәм калалар тарихынан”(Казан,1997 ел ) исемле хезмәтендә түбәндәге юллар бар: “Акъегет авылы янында археологлар борынгы Болгар чорына нисбәтле табылдык әйберләр билгеләгәннәр“ .

Авылыбызның исемен русчалап Елеметова – Акзегитова дип тә язган очрак бар, Елеметова дип тә язганнар. Кем ничек ишеткән шулай язган күрәсең. Авыл исемен һәм аңа кайчан нигез салынуын ачыклау бик тә читен мәсьәлә булып калган Республикабызның Чүпрәле районынла Тәтеш

шәһәреннән 100 км ераклыкта урнашкан Ильметьево авылы бар.Авылыбызныңисеме бу авыл белән бәйләнмәгәнме икән?

Мин бу сорауга җавапны Чүпрәле районы авыллары тарихы язылган китаптан (Р.С.Субаев.”Чүпрәле:узган еллар,үткән юллар”.2000 ел 393бит.) эзләп табарга тырышып карадым. “Чепкас – Илмәт авылы Татарстан Республикасы картасында Ильметьево дип язылган. Авыл аксакаллары монда нигез салучы кешенең исеме Илмәт исемле булуы турында сөйләп калдырганнар. Бу язмада авылның исеме Акъегет белән бәйле булуы ачыклана. Гомумән алгандаТау ягы авыллары Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорларында ук нигезләнүе тарихта билгеле. Безнең Акъегет авылы да шул вакытларда оешкан дип әйтү бик урынлы. Югарыда язылганнарны дәлилләп Казан Дәүләт Университеты профессоры Гомәр Саттаров болай дип яза: “Тау ягының Яшел Үзән районына караган авылларның тарихы шактый кызыклы,тирән эчтәлекле һәм игътибарга лаек”-ди. Ул авылларның исемнәре:Муллаиле,Татар Әҗәле,Норлат,Күгәй,Күгеш,Акъегет,Бакырчы,Юынчы. Авылларның оешуы бик озак еллар дәвамында,бик күп шартлар тәэсирендә барган.Элек авыллар куе урман эченә урнашканнар. Авыл зурая барган саен чәчү җирләре күбрәк кирәк булган.Урманнарны кисеп,йортлар салганнар,каралты –кура корганнарһәм чәчү җирләрен зурайтканнар.Урман кисүдә авылның бөтен халкы катнашкан,чөнки урманны кисү, аны чистарту,яндыру күп көч сораган. Шулай да шактый озак еллар дәвамында куе урманлыклар сакланып калганнар. Акъегет авылы тирәсендә урманнарның шактый зур булуын раслый торган чыганаклар бар. Акъегет авылының җирләре Чувашстанның (Мусирма-Бүшәрем Башы) авылына шактый якын урнашкан.Авыл халкы арыш,бодай, борчак, ясмык, карабодай, солы, киндер, тары чәчеп үстергән.Элек бәрәңге игелмәгән.

Авыл халкы ат, сыер,кәҗә, сарык һәм кош –корт асраганнар. Ярлы кешеләр кәҗә асраганнар. Мондый кешеләр авылда күп булган. Югарыда язылганнардан чыгып,ул заманда авыл халкы тормышының нинди авыр

булуын күз алдына китерү читен түгел. Халыкның киеме киндер тукымадан тегелгән,аяк киеме юкә кабыгыннан эшләнгән чабата һәм агач башмак булган. Кышын хәлле кешеләр тун кигәннәр,ә соңыннан киез итек кия башлаганнар. Авыл кешеләре тирә-як күрше авыллар белән элемтәдә булганнар,сәүдә иткәннәр. Мәсәлән, борынгы заманнарда ук хәзерге Городище авылы янында Өтәк каласы булган. Анда бик еш ярминкәләр үткәрелгән. Тирә - як авыллардан монда мал-туар,иген һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары алып килеп сатканнар.(Идел ягы газетасы, 1969 нчы,ел №178.Г.Саттаров). Безнең авылдан Өтәк 25 км ераклыкта,бу ара ерак түгел. Безнең авыл кешеләре крепостной булмаганнар,ләкин ул чактагы авырлыкларны үз җилкәләрендә татыганнар.

1860 нчы ел реформасыннан соң Россиядә капитализм көчәя. Шахталар, алтын приискалары, яңа завод-фабрикалар ачыла, яңа тимер юллар салына. Һөнәрчелек үсә. Сәүдә көннән-көн киң колач ала бирә. Аның йогынтысы безнең авылга да тәэсир итми калмый. Авыл халкының төп кәсебе игенчелек һәм терлекчелек була. Сибгатуллин Нәбиулла бабайда 1893 нче елда авыл халкына имана җире бүлеп биргән һәм имана өчен акча җыйган исемлекнең төп нөсхәсе сакланган. Ул исемлек соңыннан Гыйзатуллин Габбазга биргән. Ул исемлек гарәп хәрефләре белән тушь белән язылган булган. Исемлектә күрсәтелгәнчә,1893 елда Акъегет авылында 362 ир кешеле хуҗалык булган һәм яңа туган балаларны кертеп авылда 2150 чамасы кеше яшәгән дип әйтеп була.

Авылда эчү өчен суы бик тәмле булган Имани кизләве белән Йосыф кизләве бар. Аларның исемнәре кеше исемнәре белән бәйләнгәне күренеп тора. Имани исемле кеше беренче булып су чыганагын таба, ә Йосыф үзе бакчасында булган сучыганагын чистарта һәм урамга чыгара. Авылда барлыгы 12 кое була. Алар Бөек Ватан сугышы елларында күмелгәннәр.

Авыл җәй көннәрендә яшеллеккә күмелгән, чөнки авылда алма,җиләк –җимеш бакчалары бик күп була.Үзенең алма бакчалары белән авылым дан тоткан.Өч су тегермәне булган.Аларның һәрберсенең исеме булган.Авылда

киез итек басу һөнәре тиз таралып китә. Ирләрнең күбесе бу һөнәргә тиз өйрәнә. Итекчеләр кышын читкә чыгып чуваш авылларында да йорттан – йортка йөреп итек басканнар. Бу һөнәр әле хәзер дә авылда саклана. Авылда балта осталары да күп була. Революциягә кадәр аларның көнлек хезмәт хакы 15-20 тиеннән артмаган. Авыл халкы кирпеч сугу белән дә шөгыльләнә. 1800 нче елларда 100 кирпеч бәясе 1 сум булган дип сөйләгәннәр авыл картлары. Авыл уртасында, Бүшәрмә елгасының уң як ярында тимерчелек була. Анда атлар дагалыйлар,сука, сабан тимерен таптыйлар башка күп эшләр башкаралар.

Бизәнү әйберләре ясау - борынгы болгар бабаларыбыздан буыннан-буынга калып килгән һөнәрләребезнең берсе. Алтын һәм көмештән балдак, йөзек, чулпы ясаганнар. Бу бизәнү әйберләре безнең татар халкында бик киң таралган һәм хатын-кызларга гүзәллек өстәп торган. Җитештерелгән барлык төр һөнәрчелек әйберләре сатар өчен дә эшләнә. Сату –алуны алып баруда күрше Кәвәл авылындагы, Чувашстандагы базарлар зур роль уйнаган.Элек бу базарлар бик зур булганнар,бик күп төрле товарлар сатылган, сәүдәнең үсешенә этәргеч булган. XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасыр башында һөнәрчелек һәм сәүдә киң колач ала. Авылда зур байлар һәм үзләренең кибетләрен тотучы, сәүдә итүчеләр килеп чыга. Авылыбызның күп кенә кешеләре чит шәһәрләрдә үзләренең кибетләрен ачып сәүдә итәләр,зур байлыклар туплыйлар. Болар арасында зур байлыкка ия булган миллионер сәүдәгәр авылдашыбыз Заһидулла Шафигуллин аерылып тора. 1861 нче елгы реформадан соң Заһидулла ике дә уйлап тормыйча ,Себергә китә һәм Тайгага кадәр барып җитә. Бәхетен эзли һәм алтынга бай урынны таба.1868 нче елларда аның инде Чита, Иркутск, Красноярск шәһәрләрендә кибетләр ача,мехлар сата. 1876нчы елда туган авылы Акъегеткә кайта. Иң беренче эш итеп авылда мәктәп салдыра,манаралы мәчет бурасы буратып,яңадан Себергә юл тота.Олыгая төшкәч,Заһидулла Шафигуллин авылга кайтып урнаша.Чардаклап агачтан эшләнгән ике катлы бик матур йорт салдыра.Ике катлы йорт каршына

балконлы кунак йорты салдыра. Су бассейны булган,зур алмагач һәм җиләк-җимеш бакчасы үстерә. Ишек алдында дүрт баганалы тимер капкалар,сарайлар була. Берникадәр вакыттан соң тагын ике мәктәп салдыра.Акъегеттә –кызлар өчен (бүгенге көндә тарихы архитектурасын югалтмыйча саклап калып, мәчет итеп үзгәртелгән бина. Мәчет, авылыбыз мулласы Тимуршин Фәргат җитәкчелегендә төзекләндерелеп, авыл уртасында балкып тора), ә Чүтидә - малайлар өчен.Бакырчыда манаралы мәчет төзетүгә ,зур суммада акча бүләк итә.Заһидулла аганың бу игелекле эшләренә бар да соклана.

Соңрак ул тагын бер мәдрәсә –мәктәп салдыра Бу мәктәптә танылган язучы Зариф Бәшири (1882-1962) укыган чакларын искә алып,андагы укыту-тәрбия эшенең куелышы турында үзенең “Замандашларым белән очрашулар “(Казан, 1968 ел) исемле китабында менә нәрсәләр яза: ”Хәзер миңа ундүрт яшь... Шул гомернең дүрт елы мәдрәсәдә үтте. Бакча эчендә салынган ике катлы зур мәктәп. Аның түбәнге катында җыйнак бүлмәләрендә читтән килеп укучылар тора. Югары катында уку,класс бүлмәләре. Пакъ,таза, бөтен җирләре балавыздай итеп юылган һәм кара парталар тезелеп киткән, бу бүлмәләргә кергәч тә,үземне яңа дөньяга чыккандай хис иттем һәм күз алдыма Буа мәдрәсәсе ыржаеп килеп баскандай булды. ...Мәктәп ишек алдында мунча төзелгән.Шәкертләр атна саен шунда кереп юыналар.Зур ашханә.Анда һәрвакыт куб кайнап тора.Теләгән вакытында чәеңне эчә бир.Дүрт ел уку дәверендә һич шикләнми шуны әйтә алам:бу мәктәп минем аңымны,дөньяга, тормышка булган карашымны киңәйтеп мине начармы-яхшымы, әдәбият мәйданына кертеп, матбугат хезмәтчесе ясады!”.

Өлкән әдибебез Афзал ага Шамов Татар Танае авылыннан килеп Заһидулла мәдрәсәсендә укый. Бу хакта ул 1996 нчы елның 30 нчы мартында өлкән укытучыбыз Әлмиев Альфред абыйга язган хатында менә нәрсәләр хәбәр итә: “Мин Заһидулла мәдрәсәсендә Акъегеттә 1915-1916 нчы елларда укыдым. Бай мәдрәсәдә рус класслары бар иде.Мин аны

Акъегеттә тәмамладым.Анда безне өч укытучы укытты. Шуларның берсе-Фатих Сәйфи-Уфалы иде. Әй,авылкай! Кемнәр кушты синңа бу исемне”Акъегет” дип?...17 яшемдә синңа килеп суларыңны эчтем, юлларыңнан йөрдем, сөттән ак,судан саф булып килдем сиңа,шулай ук керсез, саф көенчә киттем синнән.Шулай булгач ник сагынмыйм, ничек онытыйм сине?Онытмыйм һаман да яшь, матур булып синең урамнарыңда йөрим”.Шулай итеп, мин Заһидулла Шафигуллинны туган мәктәбемә нигез салучы мәгърифәтче дип горурланып әйтә алам.

**Заһидулла Шәфигуллин авылыбыздан чыккан күренекле шәхесләрнең берсе булса, ул исемлекне тагын дәвам иттерер идем.**

**Авылыбызның күренекле шәхесләре:**

1. Әлмиев Хәйретдин –ветеринария фәннәре галиме. Профессор.
2. Каюм Саттаров – татарлар арасыннан чыккан беренче диңгез капитаны.
3. Һашим Саттаров- техник фәннәр кандидаты. Диңгезче.
4. Сәмитов Рәүф – полковник. Финансист. Озак еллар оборона министрлыгында эшләгән.
5. Әлмиев Усман- Татарстан халык артисты.Хезмәт Кызыл байрак ордены кавалеры.
6. Динә Сиражетдинова – халык җырчысы, артист.
7. Мәрьям Хисамова – курчак театры артисты.
8. Әбүбәкеров Гәрәй – Социалистик Хезмәт герое. Шахтер.

## Йомгаклау.

Авылымның алдагы тормышы мине бик борчый, чөнки минем әби-бабаларым да, әти-әнием дә һәм мин үзем дә шушы авылда туып үскән. Мин аның язмышына битараф түгелмен.

Шушындый үзенчәлекле һәм ямьле авылда туганыма мин бик сөенәм. Һәр яңа көн тугач, Акъегетнең тагын да гүзәлрәк күренешләрен күреп сокланам, үземә яңалык итеп алам. Бүгенге матурлыгын күрә алу – бер бәхет,

ә инде аның үткән хатирәләрен белү – мең бәхет. Шуңадырмы, мин шушы эшкә зур теләк һәм кызыксыну белән алындым. Авылымның тарихын өйрәнү өчен барлык мөмкинлекләрдән дә файдаландым. Әби-бабайлардан сораштыру, тарихи документларга мөрәҗәгать итү, иптәшләрем белән берлектә нигез тарихын өйрәнү – болар барысы да минем хезмәтемдә чагыла. Киләчәктә дә тарихлар язылу дәвам итсен, авылларның матурлыгы, кешеләрнең уңган булуы башка буыннарга барып җитсен иде. Чөнки үткәнен белмәгәннең, киләчәге дә юк.

**Файдаланылган әдәбият.**


1. Тимершин И. Акъегет авылы тарихы сәхифәләре.Казан, 2001.-164 б.
2. Идел аръягы мәшһүр шәхесләре эзеннән /Төзүче автор Г. Р. Саттарова. – Казан: ГБУ, 2013. -264 б.
3. Мәгърифәт нурлары балкышы.Казан: Саттарова Г. Р.,”Школа” редакция –нәшрият үзәге, 2016.-200 б.
4. Гарипова Ф. Г. Авыллар һәмкалалар тарихыннан. Казан, 1997.
5. Г. Саттаров. Яшел Үзән районы авылларының исемнәре. Казан.
6. “Идел ягы” газетасы.- 1998. - №95-96.
7. Бәшири З. Замандашларым белән очрашулар. Казан, 1968.
8. Субаев Р. С. Чүпрәле: узган еллар, үткән юллар. 2000.
9. М. Мәһдиев. “Акъегет егетләре” (Идел ягы. 1991 ел).

# Анкета участника

| | |
|---|---|
| Ф.И.О. участника | Миннәхмәтова Зәринә Расих кызы |
| Тема исследовательской работы | Акъегетем – туган авылым. |
| Секция | История населенных пунктов (деревень, городов) Горной стороны. |
| Почтовый адрес места жительства участника | РТ Зеленодольский район с. Акзигитово ул. Джалиля, дом 1 |
| Телефон участника | |
| Адрес электронной почты участника (указывать точно) | daniya2703@mail.ru |
| Ф.И.О. научного руководителя (учителя) | Закирова Дания Минулла кызы |
| Телефон научного руководителя (учителя) | 89376129458 |
| Название места учебы участника и работы научного руководителя (общеобразовательного учреждения) | МБОУ «Акзегитовская ООШ им. У.Альмеева ЗМР РТ» |
| Почтовый адрес общеобразовательного учреждения | gelinya@mail.ru |
| | |